**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары**
**(мәктәп туры, 2015-2016 уку елы)8 нче сыйныф**
**Башкару вакыты – 90 минут**
**Гомуми балл - 100**

**I. Әдәбият теориясенә караган биремнәр.**

1. Әлеге билгеләмәне дәвам итеп языгыз. (20 балл)
   Хикәя ул –.... яки суфичылык әдәбияты ул –

2. Мәгърифәтчелек әдәбиятына хас үзенчәлекләрне санагыз,үз фикерләрегезне мисаллар ярдәмендә дәлилләп бирегез. Мәгърифәтчелек әдәбиятына мөнәсәбәтле кайсы авторларның нинди әсәрләрен беләсез? (20 балл)

**II. Әдәби иҗатка караган биремнәр.**

1. Әлеге өзекләр алынган әсәрләрнең исемнәрен һәм авторларын билгеләгез (теге яки бу төркемне үзегез сайлый аласыз): (10 балл)

*“Русия уртасында Идел елгасыннан ерак түгел бер татар авылы бардыр.”*
*“Көмешләнгән бөтен өйләр, вә сахралар тора балкып.”*
*“Яшь бала елый иде.*”

*“Мин яшь вакытта безнең кыяр каравылчысы бер картыбыз бар иде.”*
*“Ай, шушы көй үзә бит минем үзәгемне.”*
*“Илем өчен илсенеп, Җирем өчен җирсенеп...”*

2. Ш.Камалның “Акчарлаклар” яки “Буранда” әсәрләрендә кайсы табигать образлары ясалма (шартлы, күчерелмә мәгънәдәге) образлар дәрәҗәсенә күтәрелә? (5 балл)

1. Ф.Кәриминең “Салих бабайның өйләнүе” яки М.Акъегетнең “Хисаметдин менла” әсәрләрендә автор күтәргән проблемаларны ачыклагыз, автор аларны чишүнең нинди юлларын идея итеп тәкъдим итә. (10 балл)

2. Ф.Кәриминең “Салих бабайның өйләнүе” яки М.Акъегетнең “Хисаметдин менла” әсәрләрендә ни өчен мәгърифәтле геройга мөрәҗәгать ителә? (5 балл)

**3. Иҗади эш. (30 балл)**

*1. Егет булса, ут булсын...* мәкален дәвам итеп бетерегез һәм шуңатаянып, үз тормышыгыздагы берәр вакыйга хакында кечкенә генә хикәя языгыз.